**Шәһәр күләмендә**
**җәмгыять белеме фәненнән үткәрелә торган**
**олимпиаданың мәктәп этабы сораулары**
**2017-18 уку елы**

**10-11 нче сыйныф.**
**Биремнәрне үтәү өчен 3 сәгать вакыт бирелә.**

**1. Лингвистик конструктор. Китерелгән сүзләрдән төшенчәнең билгеләмәсен төзегез һәм язып куегыз. Түбәндә сүз алып барыла торган төшенчәне атагыз.**

1.1. Яшәү рәвешенә, ташлап киткән, бер мәдәниятне, башкаларның, илне, һәм, кыйммәтләренә, ярашмаган, төркемне, кеше.

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
______________________________

1.2. Чикләрне бетерә, милләтләрне, кешелек дөньясын, тарихи процесс, халыкларны, һәм, якынайта, традицион, әверелдерә торган, акрынлап, һәм, бердәм системага

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
______________________________

**2. Сорауга җавап бирегез. Әгәр сезнең җавабыгыз түбәндәге гыйбарә белән туры килсә әйе, туры килмәгәндә юк дип билгеләгез.**

2.1. Кайбер очракларда тумыштан килгән (прирождённый) социаль статус үзгәрергә мөмкин.

2.2. Дәүләтнең барлыкка килүен дәлилләүче өч төп иҗтимагый килешү теорияләре авторлары булып Т. Гоббс, Н. Макиавелли һәм Ж.Ж. Руссо исәпләнәләр.

2.3. Культурология фән буларак җәмгыять тормышының барлык якларын өйрәнә.

2.4. Олигополия өлкәсендә монополиягә караганда җитештерүчеләр күбрәк була.

2.5. Мәктәпнең үзешчән сәнгать ансамбле формаль булмаган төркемнең мисалы.

2.6. Ата-аналардан һәм аларның кияүгә чыкмаган (өйләнмәгән) балаларын үз эченә алган гайлә нуклеар гайлә дип атала.

2.7. Матди булмаган мәдәният кеше кулы белән тудырылган физик объектлар.

2.8. РФ Федераль Җыелышының төп бурычы дәүләт бюджетын үтәүне тормышка ашыру булып тора.

Җавап:

| 2.1 | 2.2. | 2.3 | 2.4 | 2.5 | 2.6 | 2.7 | 2.8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

**3. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавап астына сызып куегыз.**

3.1. Өстенлек итүче мәдәниятләр эчендәге автономияле оешмаларны чагылдыручы, яшәү рәвешен һәм фикерен билгеләүче яшьләр оешмасының нинди аерым формасы аңлата?

1) яшьләр инфантилизмы
2) яшьләр субмәдәнияте
3) гомуми мәдәният
4) поп-арт

3.2. Милли дифференциациянең көчәюе нәрсәгә омтылыш тудыра?
1) милләтара элемтәләрнең киңәюенә
2) милли киртәләрнең җимерелүенә
3) башка милләтләр белән икътисади мөнәсәбәтләрнең тирәнәюенә
4) милли үзлегеңнән үсешкә

3.3. Законлы хакимият иректе һәм яхшы күңелле кешеләрнең үз теләкләре белән килешүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән, дип раслаучы тәгълимат– ул:
1) патриархаль теория
2) психологик теория
3) җәмгыять килешүе теориясе
4) хакимиятне бүлгәләү теориясе

3.4. Пропорциональ сайлау системасы мажоритардан нәрсә белән аерылып тора?
1) сайлаулар гомуми һәм тигез үткәрелә
2) үз округында күпчелек тавыш алган кандидат җиңүче итеп таныла
3) сайлау участокларында тавыш бирү яшерен рәвештә үткәрелә
4) сайлаучы сайлау берләшмәләре яисә партияләре кандидатлары исемлекләре өчен тавыш бирә

3.5. Хәзерге Рәсәй җәмгыятенең социаль стратификациясе нәрсәдә күренә?
1) җәмгыятьне төрле социаль төркемнәргә бүлгәләүдә
2) иҗтимагый тотрыклылыкны югалтуда
3) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен киңәйтүдә
4) дәүләтнең халыкның аз тәэмин ителгән катлауларына булышлык итүендә

3.6. Хакимиятнең вәкиллекле органнарының яртысын үз партия һәм хәрәкәтләренең сайлау исемлекләренә кертелгән, ә яртысын – бермандатлы округларда күпчелек тавыш алган кандидатлардан формалаштыру нәрсә өчен характерлы?
1) мажоритар сайлау системасы өчен
2) пропорциональ сайлау системасы өчен
3) депутатларны турыдан-туры җибәрү (делегирлау)
4) катнаш сайлау системасы өчен

**4. Әлеге рәтләр нинди принцип буенча төзелгән? Алар өчен уртак булган төшенчәне билгеләгез**.

4.1. Мәгариф, чиркәү, хезмәт коллективы, гаскәр.

______________________________________________________________________

4.2.Дәүләт, гаскәр, икътисад, юстиция, сәламәтлекне саклау

_____________________________________________________________________

4.3.Социальләшү, икътисади куркынычлылыкны тәэмин итү, яңадан җитештерү (воспроизводство), эмоциональ ярдәм.

________________________________________________________________________

**5. Түбәндә китерелгән рәтләрдән артык элементны табыгыз һәм астына сызыгыз. Үз җавабыгызны аңлатыгыз.**

5.1. Белем алу, уңышлы өйләнү, сәяси режимның алмашуы, хакимият органнарына сайлану.

______________________________________________________________________________________________

________________________________________________________

5.2. Сәүдәгәрләр, казаклар, буржуа, мещаннар

______________________________________________________________________________________________

________________________________________________________

5.3. Демократия, олигархия, коллегиальлек, аристократия

______________________________________________________________________________________________

________________________________________________________

**6. Рәттә төшеп калган сүзне языгыз.**

6.1. Кабилә, ____________________________________, милләт.

6.2. Көч, __________________, абруй

**7. Курсив белән билгеләнгән өлешне юридик термин белән алыштырыгыз.**

**7.1.** Хезмәт хокукында *эшченең төп хезмәт документы* булып _________________________________ тора.

7.2. Кайбер очракларда *чит ил гражданнарын мәҗбүри рәвештә РФ территориясеннән чыгаралар*. Бу __________________ дип атала.

7.3. Чит илгә чыгу паспортында *башка илгә керер, анда йөрер, чыгар өчен махсус рөхсәт билгесе* куела. Ул ______________________дип атала.

7.4. *Аңлы рәвештә башка кешенең фәнни, әдәби яисә сәнгать эшенең авторлыгын өлешчә яисә тулысынча үзенеке итеп күрсәтү* ___________________ дип атала.

**8. Чит телләрдән кергән җәмгыять белеме терминнарын аларның турыдан-туры тәрҗемәләре белән туры китерегез.**

| термин | тәрҗемә |
|---|---|
| 1. Фәлсәфә | А) китап |
| 2. Этнос | Б) акыллылыкка мәхәббәт |
| 3. Коръән | В) халык |
| 4. Тотем | Г) буысынучанлык (покорность) |
| 5. Дин | Д) хикәяләү (повествование) |
| 6. Ислам | Е) борынгы баба (предок) |
| 7. Библия | Ж) бәйләнешле булу |
| 8. Миф | З) уку |

Җавап:

| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. | 6. | 7. | 8. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

**9. Анаграмманы чишегез. (хәрефләрне үз урынына куеп, җәмгыять белеменә караган сүзне языгыз).**

А) оюрбиаркят

Б) еенртсвиияацз

В) ооиглоиялп

Г) яикциатфтсиар

Д) аатрншәм

Е) ртнтоэмцнези

**10. Түбәндәге ситуацияләрне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз.**

10.1. Ир кеше аерылышу нияте белән ЗАГС органнарына гариза белән мөрәҗәгать итә. ЗАГС хезмәткәрләре әлеге кешенең балигъ булмаган кызы булуын ачыклагач, гариза кабул итүне кире кагалар. Әлеге гражданин ЗАГС хезмәткәрләренең гамәлләре аның хокукларын бозуы турында белдерә.

**Бу очракта ЗАГС хезмәткәрләре хокуклымы? Үз җавабыгызны аңлатыгыз.**

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________

10.2. Баланы күршеләрнең эте тешли. Өйгә ул ертык курткасы һәм шактый каты кул җәрәхәте (травма) белән кайта. Баланың әти-әниләре күршегә дәгъва (претензия) ясарга килгәч, ул аларга гаепле булмавын, баланың артык каты куллары белән селтәвен һәм әлеге кискен хәрәкәтләргә этнең тәэсирләнүен белдерә.

**Бу очракта күрше хокуклымы? Баланың әти-әниләре җәрәхәтне дәвалау компенсациясен алу өчен нәрсә эшли алалар?**

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________

**11. Сезнең алда төрле социаль берлекләрнең исемнәре. Аларны өч төркемгә бүлергә мөмкин. Аларның берсе таблицада күрсәтелгән. Калган ике төркемне билгеләгез һәм таблицаның өстәге юлына язып куегыз. Соңыннан сан белән китерелгән социаль берлекләрне таблицаның туры килгән баганаларына язып куегыз.**

1. Дворяннар. 2. Брахманнар. 3. Квалификацияле белгечләр. 4. Крестьяннар. 5. Вайшьяләр. 6. Дәүләтнең идарә хезмәткәрләре. 7. Казаклар 8. Кшатрияләр. 9. Мещаннар

| Страталар | | |
|---|---|---|
| | | |

**12. Беренче баганадагы хезмәтләрне (әсәрләрне) аларны иҗат итүче акыл ияләре исемнәре белән туры китерегез. Игътибар итегез, акыл ияләренең исемнәре хезмәтләргә караганда арыграк.**

| **Хезмәтләр** | **Акыл ияләренең, галимнәрнең исемнәре** |
|---|---|
| 1. “Үткәннәр һәм уйланулар” («Былое и думы»)<br>2. «Коммунистлар партиясе манифесты»<br>3. «Философик хатлар»<br>4. «Рәсәй һәм Аурупа»<br>5. «Бөтеньдөнья тарихы буенча язмалар» | А) А. Хомяков<br>Б) П. Чаадаев<br>В) А. Герцен<br>Г) Н. Данилевский<br>Д) К. Маркс<br>Ж) П. Сорокин<br>З) Г. Гегель |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**13. Схемага җитешмәгән мәгълуматны язып куегыз.**

Гомуми керем – 1. = Икътисади табыш

Гомуми керем – Тышкы чыгымнар = 2.

Бухгалтер чыгымнары + 3. = Икътисади чыгымнар

**14. Беренче баганадагы төшенчәләрне аларның билгеләмәләре белән туры китерегез.**

| **Төшенчәләр** | **Билгеләмәләр** |
|---|---|
| 1) Лоббизм | А) Дәүләт тарафыннан илгә товарлар кертүне һәм чыгаруны тыю |
| 2) Эмбарго | Б) Товар сатучы фирмага табыш китерми торган, ясалма арзан бәядән сату. |
| 3) Демпинг | В) Эре сатучылар арасында базарны бүлү һәм бәяләрне билгеләү турындагы килешү. |
| 4) Картель | Г) Законнар чыгаручы хакимият органнарында депутатлар фракциясе төзү юлы белән билгеле бер агентлар төркеменең ихтыяҗларын кәнагәтләндерүче легаль форма |

| **1** | **2** | **3** | **4** |
|---|---|---|---|
| | | | |

**15. Түбәндәге исемлектән демократик җәмгыятьнең сайлау системасына мәҗбүри таләпләр үрнәкләрен табыгыз.**

1) милек цензы
2) сайлауларның альтернативасыз булуы
3) гражданлык цензы
4) яшерен тавыш бирү
5) гражданнарның тавышларының тигезлеге
6) сайлау көнне сайлау алды агитациясе үткәрү

**Сайлап алынган цифрларны үсә бару тәртибендә языгыз.**

Җавап: ________________________________________.


**16. Төрле милек формалары булган предприятияләр һәм аларның сыйфатламалары арасындагы тәңгәллекне табыгыз: беренче баганада бирелгән һәр позициягә икенче баганада тәңгәл килүче позицияне сайлап алыгыз.**

| ХАРАКТЕРИСТИКАЛАР | ПРЕДПРИЯТИЕ ФОРМАЛАРЫ |
|---|---|
| А) кыйммәтле кәгазьләр чыгарырга хокуклы | 1) Акционерлык җәмгыяте |
| Ә) идарә итүне сайлап куела торган вәкилләр тормышка ашыра | 2) Җитештерү кооперативы |
| Б) гражданнарның хезмәттә шәхсән катнашуына нигезләнгән | |
| В) эшченең табышларның бер өлешенә хокукы ул эштән киткәч тә саклана | |
| Г) керем әгъзаларның хезмәттә катнашуына бәйле рәвештә бүленә | |

**Сайлап алынган саннарны таблицага язып куегыз.**

| А | Ә | Б | В | Г |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**17. Схемада төшеп калган сүзләрне языгыз**



**18. Түбәндә билгеле һәйкәл - символлар сурәтләнгән. Аларның исемнәрен, кайда урнашканың һәм нәрсәне символлаштырганың языгыз.**

1. 
2. 

3. 
4. 

1.______________________________________________________________

______________________________________________________________

2. ______________________________________________________________3.______________

______________________________________________________________

______________________________4.______________________________

______________________________________________________________

**19. Түбәндә тәкъдим ителгән өземтәләрнең <u>берсен</u> сайлап алыгыз һәм күтәрелгән мәсьәлә буенча үз фикерегезне (карашыгызны, мөнәсәбәтегезне) бәян итегез. Үз карашыгызны нигезләү өчен <u>дәлилләр</u> китерегез.**

**Биремне үтәгәндә җәмгыять белеме курсыннан алган белемнәрегезне, туры килгән төшенчәләрне, шулай ук иҗтимагый тормыш фактларыннан һәм үз тормыш тәҗрибәгездән файдаланыгыз.**

**Темалар:**

1. «Халыкара сәясәт, барлык башка сәясәтләр кебек үк, хакимлек өчен көрәш ул» (Г. Моргентау).
2. «Хезмәт кешенең дәрәҗәсен күтәрә» (В.Г. Белинский).
3. «Ирекле милләт кенә милли характерга ия була ала» (Ж. де Сталь).
4. «Дефицит – ул бөтен нәрсәнең булуы, әмма кайда булуы билгеле булмау» (Д. Гвилава).
5. «Йомшак законнарга сирәк буйсыналар, катылары исә бик сирәк тормышка ашырылалар» (Б. Франклин).
6. «Икътисад ул чикләнгән ресурслар ярдәмендә чиге булмаган ихтыяҗларны канәгатьләндерү сәнгате» (Л. Питер).

7. «Сәясәттә үз иленә яисә үз сайлаучыларыңа хыянәт итәргә туры килә. Мин икенчесен кулай күрәм» (Ш. Де Голль).